СОВЕТ
МОЛВИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУЛЛА ИЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2024 ел Мулла Иле ав. **№ 174**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Мулла Иле авыл җирлеге Советы карар чыгарды::

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Мулла Иле авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Мулла Иле авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2024 елның 06 маендагы 151 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) , шулай ук Мулла Иле авылы, Яна урам, 3 (җирлекнең административ бинасы), Мулла Иле авылы, Үзәк урам, 17а йорты (мәдәният йорты бинасы),Зур Отэк авылы ,

Яшел урам, 21а йорты (мәдәният йорты бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга

Мулла Иле авыл жирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Г.Сәлахиев